СОВЕТ УТЯШКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Центральная, д.10,
с. Татарское Утяшкино,423186

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ӘДӘМСӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урамы, 10
Әдәмсә авылы,423186

тел.: (8-84348) 3-47-41, факс: (8-84348) 3-47-65, Ut.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Әдәмсә авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

22 октябрь 2020 ел №3-8

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Әдәмсә авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәренең даими нигезендә муниципаль вазыйфасын башкаручы затларга акчалата түләү күләмен арттыру турында »

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын арттыру», «җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТӘ:

1. Яңа Чишмә муниципаль районы Әдәмсә авыл җирлеге Советының «даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларга акчалата бүләкләүләр, Яңа Чишмә муниципаль районы Әдәмсә авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр билгеләү турында» 2018 елның 1 октябрендәге 47-98 номерлы карары белән расланган даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга айлык акчалата түләү күләмен, Яңа Чишмә муниципаль районы Әдәмсә авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең айлык һәм

башка өстәмә түләүләр күләмнәрен 2020 елның 1 октябреннән 1,03 тапкырга арттырырга, (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Әдәмсә авыл җирлеге Советының 2018 елның 14 декабрендәге 49-108 номерлы, 15.06.2020 ел, № 67-148 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән).

2.Әлеге карарны Интернет «мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге» Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (http://pravo.tatarsta.ru) һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә)

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Әдәмсә авыл җирлеге Башлыгы И.Ф. Гибадуллин

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «УТЯШКИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
р 06-594/14
СОВЕТ УТЯШКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ